Республика Татарстан

Совет Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы Советы

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

2021 елның 13 апреленнән Менделеевск ш. № 46

«Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына
озак сроклы нигездә файдалануга бирү өчен
«Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең муниципаль мөлкәтен
(кече һәм урта эшкуарлык субъектларының
мөлкәти хокукларыннан тыш) арендага бирү
тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы Советының
2017 елның 04 апрелендәге 98 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 20-ФЗ номерлы Федераль законның 1 һәм 2 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 08 июнендәге 169-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру максатларында,

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы **КАРАР БИРӘ:**

1. Озак сроклы нигездә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына файдалануга бирү өчен «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль мөлкәтен арендага бирү тәртибен раслау турында» 2017 елның 04 апрелендәге 98 номерлы Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы карарына өченче затлар хокукларыннан ирекле (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының 2017 елның 04 апрелендәге 98 номерлы карарына исемдә «кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга бирү» сүзләреннән соң «кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче, махсус салым режимын кулланучы физик затларга» сүзләрен өстәргә.

2) Тәртиптә «кече һәм урта эшкуарлык субъектларын яклау инфраструктурасын барлыкка китерүче» сүзләреннән соң «махсус салым режимын кулланучы физик затларга» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Менделеевск

муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Совет рәисе В.С.Чершинцев